**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.10.2019 №795

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районында КФҮ филиалында күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында» 2018 елның 26 ноябрендәге 969 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районында КФҮ филиалында күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында» 2018 елның 26 ноябрендәге 969 номерлы карарына, карар исемен түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Татарстан Республикасында КФҮ ДБУның Кама Тамагы филиалында күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында».

2. Татарстан Республикасында КФҮ ДБУның Кама Тамагы филиалында кушымта нигезендә күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеген яңа редакциядә расларга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Р.М. Заһидуллин

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның 2 октябрендәге
795 номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасында КФҮ ДБУның Кама Тамагы филиалында күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеге**

| | |
|---|---|
| 1 | Күпфатирлы йортта бинаны үзгәртеп коруны һәм (яки) үзгәртеп планлаштыруны килештерү турында карар кабул итү |
| 2 | Бинаны торак урыны, Торак урынын яшәү өчен һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт дип һәм торак йортны бакча йорты дип тану |
| 3 | Торак (торак булмаган) бинаны торак булмаган бинага күчерү (күчерүдән баш тарту) турында хәбәрнамә бирү |
| 4 | Төзелешкә рөхсәт бирү |
| 5 | Индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе (туры килмәве) турында хәбәрнамә юнәлеше һәм шәхси торак төзелеше объектын яки җир кишәрлегендә бакча йортын урнаштыруның рөхсәт ителүе (рөхсәт ителмәве) |
| 6 | Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү |
| 7 | Индивидуаль торак төзелеше яки бакча йортының төзелгән яки үзгәртеп корылган объектының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе (туры килмәве) турында хәбәрнамә җибәрү |
| 8 | Планлаштырылган капиталь төзелеш объектын сүтү турында хәбәрнамә һәм документлар җибәрү |
| 9 | Капиталь төзелеш объектын сүтүне тәмамлау турында хәбәрнамә җибәрү |
| 10 | Рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү |
| 11 | Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү |

| | |
|---|---|
| 12 | Инженерлык челтәрләренең һәм коммуникацияләрнең трассалар схемасын килештерү |
| 13 | Ана (гаилә) капиталы акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган индивидуаль торак төзелеше объектын төзү (реконструкцияләү) буенча төп эшләр башкарылуын раслаучы документ бирү |
| 14 | Җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү турында карар кабул итү |
| 15 | Җирлекнең генераль планыннан өземтә бирү |
| 16 | Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итү буенча мәгълүмат системасында булган мәгълүматларны бирү |
| 17 | Җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү |
| 18 | Адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару |
| 19 | Белешмә (өземтәләр) бирү |
| 20 | Агач һәм куакларны кисүгә, кронировкалауга яки утыртуга рөхсәт бирү |
| 21 | Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү |
| 22 | Территорияләрнең кадастр планында җир участогының яки җир кишәрлекләренең урнашу схемасын раслау |
| 23 | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген даими (сроксыз) файдалануга бирү |
| 24 | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген бушлай бирү |
| 25 | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген түләүсез файдалануга бирү |
| 26 | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген сатуларны үткәрмичә сату |
| 27 | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген сатуларны үткәрмичә арендага бирү |
| 28 | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген җир кишәрлегендә урнашкан биналар, корылмалар милекчеләренә милеккә яки арендага бирү |
| 29 | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген аукцион формасында үткәрелә торган сатуларда арендага бирү |

| | |
|---|---|
| 30 | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген аукцион формасында уздырыла торган сатуларда сату юлы белән милеккә бирү |
| 31 | Дәүләт яисә муниципаль милектә булган җирләрне һәм (яисә) җир кишәрлекләрен һәм шәхси милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү |
| 32 | Муниципаль милектә булган җир яки җир кишәрлегеннән файдалануга рөхсәт бирү |
| 33 | Аерым максатларда ачык сервитут билгеләү |
| 34 | Муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлеген алып бару өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларына милеккә (арендага) бирү |
| 35 | Муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен торак пункт чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен гражданнарга милеккә (арендага) бирү |
| 36 | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген гражданнарга бакчачылык алып бару өчен милеккә (арендага) бирү |
| 37 | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген гражданнарга дача хуҗалыгын алып бару өчен милеккә (арендага) бирү |
| 38 | Шәхси яки муниципаль милектәге җир кишәрлеген бер категориядәге җирләр составыннан (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш) башка категориягә күчерү турында карар кабул итү |
| 39 | Җир кишәрлегеннән даими (сроксыз) файдалану хокукын яки җир кишәрлегеннән гомерлек мирас итеп биләү хокукын туктату турында карар кабул итү |
| 40 | Җир кишәрлеген сатып алу турында карар кабул итү |
| 41 | Җир кишәрлеген арендалау шартнамәсенә үзгәрешләр кертү |
| 42 | Җир кишәрлекләре алу хокукына ия булган затларны исәпкә кую |
| 43 | Муниципаль милектәге җир кишәрлегенә карата сервитут билгеләү турында килешү төзү |
| 44 | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген гражданнарга шәхси торак төзелеше өчен милеккә (арендага) бирү |

| | |
|---|---|
| 45 | Муниципаль торак фондының торак урыннарын гражданнар милкенә тапшырганда документлар рәсмиләштерү |
| 46 | Элек хосусыйлаштырылган торак биналарны муниципаль милеккә кабул итү |
| 47 | Муниципаль милекне муниципаль учреждениеләргә, муниципаль казна предприятиеләренә оператив идарә хокукында һәм муниципаль унитар предприятиеләргә хуҗалык алып бару хокукында рәсмиләштерү (беркетү) |
| 48 | Муниципаль милек реестрыннан өземтә бирү |
| 49 | Муниципаль милектәге һәм арендага бирү өчен билгеләнгән күчемсез милек объектлары турында мәгълүмат бирү |
| 50 | Муниципаль казна тәшкил иткән мөлкәтне арендага тапшыру |
| 51 | Муниципаль мөлкәт реестрына керүче муниципаль мөлкәтне арендага бирү |
| 52 | Сатуларны үткәрмичә генә муниципаль берәмлек муниципаль милкен түләүсез файдалануга тапшыру |
| 53 | Муниципаль мөлкәттән түләүсез файдалану шартнамәсен мондый килешү төзү хокукына сатулар нәтиҗәләре буенча төзү |
| 54 | Муниципаль милекне арендалау буенча гамәлдәге килешүне өзү |
| 55 | Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү |
| 56 | Муниципаль милектәге өске су объектын яки аның бер өлешен файдалануга бирү турында карар бирү |
| 57 | Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга – товар, эш, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш) |
| 58 | Ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү |
| 59 | Муниципаль берәмлек чикләрендә җирле әһәмияттәге юллар буйлап тулысынча яки өлешчә үтә торган маршрутлар буенча авыр йөкләр, зур габаритлы йөкләр ташуларга рөхсәт бирү |
| 60 | Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдаланучыларга автомобиль юлларының торышы турында мәгълүмат бирү |

| | |
|---|---|
| 61 | Муниципаль преференцияләр бирү |
| 62 | Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына муниципаль мөлкәтне идарә итүгә һәм (яисә) файдалануга тапшыру |
| 63 | Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча урыннар бирүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу |
| 64 | Хезмәт торак урынын найм шартнамәләре буенча муниципаль торак фондында гражданнарга торак урыннар бирү |
| 65 | Социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән муниципаль торак фондыннан торак урыннарын алмаштыру буенча документлар рәсмиләштерү |
| 66 | Гражданга социаль наем шартнамәсе буенча муниципаль торак фондыннан торак урыны бирү |
| 67 | Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую |
| 68 | Авыл җирлегендә яшәүче гражданнарга, шул исәптән яшь гаиләләргә һәм яшь белгечләргә торак төзү (сатып алу) өчен социаль түләүләр бирү |
| 69 | “2014-2020 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү” ярдәмче программасы буенча исәпкә кую һәм торак сатып алу (төзү) өчен социаль түләү алу хокукы турында таныклык бирү |
| 70 | Торак урыннарына мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен исәпкә кую |
| 71 | Чернобыль АЭС һәлакәте, «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарга һәм аларга тиңләштерелгән затларга Дәүләт торак сертификатын бирү һәм исәпкә кую |
| 72 | Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую һәм мәҗбүри күченүчеләргә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү өчен Дәүләт торак сертификатын бирү |
| 73 | Архив белешмәләрен, архив өземтәләрен, архив документлары күчермәләрен бирү |
| 74 | Архив белешмәләрен, архив өземтәләрен, дәүләт милкенә караган һәм муниципаль архивта саклanучы архив фондлары буенча архив документлары күчермәләрен бирү |

| | |
|---|---|
| 75 | Гражданнардан законсыз саклanган яки табылган корал, сугыш припаслары, коралга патроннар, шартлаткыч җайланмалар һәм шартлаткыч матдәләр өчен ирекле тапшырылган түләүне гамәлгә ашыру өчен документлар кабул итү |